Татарстан Республикасы Ютазы мунипаль районы Акбаш авыл җирлеге Советы карары

№30 Акбаш авылы 2018 елның 22 ноябрьдән

Акбаш авыл җирлеге Советының 2018 елның 21 июненнән булган 14 санлы карарына үзгәрешләр кертү турында

2013 елның 28 декабрендәге «Иминият пенсияләре турында»гы №400-ФЗ Федераль закон, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы №131-ФЗ Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге Советының 2018 елның 21 июнендәге 14 номерлы «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Акбаш авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренә һәм даими нигездә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгу белән бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 2 пунктындагы 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгу дигәндә, картлык буенча иминият пенсиясен алу хокукын бирә торган яшькә җиткәч, муниципаль хезмәттән эштән азат ителү яки «Иминият пенсияләре турында» 28.12.2013 ел, №400-ФЗ Федераль закон нигезендә инвалидлык буенча пенсия билгеләү һәм тиешле еллар эшләгән өчен пенсия алу өчен кирәкле муниципаль хезмәт стажы булу аңлашыла.

1.2. Нигезләмәнең 3 пунктына " һәм рәсми басылып чыкканнан соң(халыкка игълан иткәннән соң) үз көченә керә" сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә www.jutaza.tatar.ru веб-адресы буенча Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Акбаш авыл җирлеге Башлыгы: Л.Р.Тимербаева